**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80.
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «12» декабреннән №29-226

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л. К. Исхакованың 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше фаразы турындагы мәгълүматны тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) Л.К. Исхакованың Яңа Чишмә муниципаль районының 2023 елга һәм 2023-2025 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында мәгълүматын игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразын хупларга.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2023 елда районның инвестицион җәлеп итүчәнлеге буенча эшне көчәйтергә;
- бизнес алып бару һәм үстерү, шулай ук район территориясендә бизнес өчен конкурентлы мохитне стимуллаштыру өчен уңайлы шартлар тудырырга;
- авыл җирлекләренең тотрыклы үсешенә, Яңа Чишмә муниципаль районы халкының мәшгульлеген һәм тормыш дәрәҗәсен арттыруга ярдәм итәргә.
4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, барлык төр милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2023 елга һәм 2024-2025 елларга план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов